**Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карары**

Азнакай шәһәре № 184-27 2018 елның "30" марты

Азнакай муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2017 елның 24 августындагы 132-20 номерлы карары белән расланган бастырып чыгару өчен бөтенроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибенә үзгәреш кертү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Азнакай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2017 елның 24 августындагы 132-20 номерлы карары белән расланган бастырып чыгару өчен бөтенроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибенә түбәндәге редакциядә «г» пунктчасын бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«г) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) сатып алу буенча алыш-бирешләр башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы муниципаль хезмәткәрнең һәм аның

хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кереméннән артып китсә. "

2. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru. Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай муниципаль районы башлыгы урынбасары Н.М. Нәгыймов өстенә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин